Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 10**

Уракчы авылы 2018 елның 21 сентябре

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Уракчы авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенә, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 20 маддәсенең 1 өлеше 1 пунктына, 2004 елның 24 мартындагы "Җирле референдум турында" 23-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 12 маддәсенең 1 пункты "в" пунктчасына, 18 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Уракчы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 19 сентябрендәге "Референдум үткәрү инициативасы турында" 29 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 сентябрендәге "Референдум үткәрү инициативасы турында" 9 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. . Җирле референдумга чыгарылучы түбәндәге сорауны расларга:

"Яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан гайре, һәрбер кешенең 2018 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм җыелган средстволарның түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә:

-Уракчы авылының Ворошилов, Совет, Комсомол урамнарында, Мельничный Пүчинкәсе авылының Заречная, Киров урамнарында, Наратлының Карбышев урамында юлларны ремонтлауга;

-Уракчы авылындагы суэтем башнясына тирәнлек насосы сатып алуга;

-кышын Уракчы авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап торуга

юнәлтүгә Сез ризамы?

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарның рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керүен билгеләргә.

4.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Пүчинкәсе авылы, Киров урамы, 20Б йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Гәрәев